**ГЛАВА ЧЕПЧУГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422736, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Чепчуги, ул.Советская,10Б

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЫПЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422736, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чыпчык авылы, Совет ур., 10Б

тел./факс 8(84365)72-5-01, e-mail:Chep.Vsg@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«1» ноября 2022 №2

**Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлегенең Чыпчык авылында халык җыенын этаплап билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, ст. 35 «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Уставының 24 статьясы, «торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында " 2019 елның 21 октябрендәге 131 номерлы карары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чыпчык авыл җирлеге составына керүче Чыпчык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы» һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чыпчык авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 12.05.2020 № 152 Совет карары редакциясендә

Карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чыпчык авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2022 елның 11 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чыпчык авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2022 елның 12 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә
3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чыпчык авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2022 елның 13 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Чыпчык авылында яшәүчеләр исемлеге гражданнар җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча бүленгән:

А) Беренче этабы - Совет урамында яшәүчеләрнең.

Б) Икенче этап - Алексеев, Дружба, Заречная , Мирная урамнарында

яшәүчеләр.

В) Өченче этап - вокзал, яңа төзелеш , Павлов, Луговая, Мәктәп урамнарында яшәүчеләр.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чыпчык авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару белән килешәсезме:

1) Мирная урамындагы юлны төзекләндерү
2) Урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру (Заречная ур., Луговая ур., Павлов ур., Школьная ур.)
3) МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу (төягеч, роторлы КРН чапкыч).

« ӘЙЕ» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны мәгълүмати стендларга һәм җирлекнең рәсми сайтына кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Бу карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Чыпчык Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы И. Р. Җиһаншин